**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 21 март № 172

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестиция проектларын тормышка ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 1999 ел, 7 май, 284 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2001 ел, 3 июль, 465 нче; 2002 ел, 5 сентябрь, 523 нче; 2005 ел, 25 август, 419 нчы; 2006 ел, 2 октябрь, 493 нче; 2008 ел, 25 август, 608 нче; 2008 ел, 26 сентябрь, 710 нчы; 2012 ел, 29 февраль, 178 нче; 2012 ел, 25 сентябрь, 799 нчы; 2013 ел, 28 март, 212 нче; 2013 ел, 31 август, 621 нче; 2015 ел, 13 июль, 512 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында инвестиция проектларын тормышка ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәгә теркәлгән 3 нче кушымтаның 14 бүлегендә:

илле өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- финанс тотрыклылыгы – Оешмаларның финанс-хуҗалык эшчәнлегенә анализ үткәрү буенча методологик рекомендацияләр (Россиянең Дәүләт статистика комитеты тарафыннан 2002 елның 28 ноябрендә расланган) нигезендә уздырыла.»;

10.4 таблицада:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Белешмә өчен: Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2001 ел, 11 март, 123 нче карары нигезендә дәүләт субсидиясе суммасы» | | | | | | | | | | | |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Белешмә өчен: дәүләт ярдәме суммасы.». | | | | | | | | | | | |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты бирү турындагы карарны килештерү

һәм кабул итү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 6 сентябрь, 642 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 14 август, 592 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты бирү турындагы карарны килештерү һәм кабул итү тәртибенең 5 нче пунктындагы утыз өченче абзацта «Кулланыла торган технологияләргә һәм техник карарларга бәйле, аларны төзүгә инвестицияләр гамәлгә ашыру инвестицияле салым кредиты бирү өчен нигез булып торган объектларның сыйфатламаларына бәйсез рәвештә югары энергетика нәтиҗәлелеге объектларына керә торган объектлар һәм технологияләр исемлеген һәм аларны төзүгә инвестицияләр гамәлгә ашыру инвестицияле салым кредиты бирү өчен нигез булып торган объектларның билгеләнгән энергетика нәтиҗәлелеге индикаторлары мәгънәләренә туры килүе нигезендә югары энергетика нәтиҗәлелеге объектларына керә торган объектлар һәм технологияләр исемлеген раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 ел, 29 июль, 637 нче карары белән» сүзләрен «Югары энергетика нәтиҗәлелеге объектларына һәм технологияләренә керә торган объектлар һәм технологияләр исемлеген раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 ел, 17 июнь, 600 нче карары белән» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\172.docx